ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫЃ ДЂЊЛЂТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236–91–44. E–mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«30» 10 2018ел № 431

Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 статьясының 3 өлешен үтәү максатында боерык бирәм:

1. Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыруның кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең түбәндәге боерыкларының көчен югалтуын таныpга:

«Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151

номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 28 гыйнварындагы 15 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 05 мартындагы 35 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 469 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 22 маендагы 145 номерлы.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә (Н.Н.Воронска) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгының 2018 елның 31 октябрендәге 431 номерлы боерыгы белән расланды

Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибе

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә (алга таба – ТР ДТИ) белешмәләр тапшыруның әлеге тәртибе «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 статьясын үтәү максатында эшләнде.

1.2. Тәртиптә түбәндәге төп терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

махсуслашкан коммерциясез оешма – функцияләре Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясында билгеләнгән, фондның оешу-хокукый формасында оештырылган юридик зат (алга таба – төбәк операторы);

махсус счет иясе – күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы һәм бер күпфатирлы йортта яки берничә күпфатирлы йортта Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба – РФ ТК) 136 статьясының 2 өлешендәге 1 пункты нигезендә оештырылган торак милекчеләре ширкәте, яки күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы торак кооперативы, яки идарә итү шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы идарәче оешма, яки күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма, – әгәр биналарның милекчеләре гомуми җыелышта төбәк операторын махсус счет иясе сыйфатында сайлау турында карар кабул иткән булса;

ТКХ ДМС (торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасы) – торак фонды, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә идарә итү буенча хезмәтләрнең, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрнең бәясе һәм исемлеге, коммуналь хезмәтләрне күрсәтү һәм коммуналь хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган ресурларны җиткерү, торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү зурлыгы, күрсәтелгән түләү буенча бурыч турында, коммуналь һәм инженерия инфраструктурасы объектлары турында мәгълүматларны, шулай ук торак-коммуналь хуҗалыгына бәйле бүтән мәгълүматларны җыюны, эшкәртүне, саклауны, бирүне, урнаштыруны һәм алардан

файдалануны тәэмин итә торган программалы, техник чаралар һәм мәгълүмат технологияләре нигезендә вазыйфалый торган үзәкләштерелгән бердәм федераль мәгълүмат системасы;

капиталь ремонт фонды – күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонтка түләнгән кертемнәр, мондый биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонтка кертемнәр түләү йөкләмәсен тиешенчә үтәмәүләренә бәйле рәвештә түләнгән пенялар, капиталь ремонт фондларын формалаштыру гамәлгә ашырыла торган махсус счетта, төбәк операторы счетында, счетларында акча чараларыннан файдаланган өчен исәпләнгән процентлар, капиталь ремонт фонды акчаларын урнаштырудан алынган керемнәр, РФ ТК 191 статьясында каралган һәм федераль бюджет акчалары, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары, җирле бюджет акчалары хисабыннан тиешенчә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бирелә торган финанс ярдәме чаралары, шулай ук күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыру өчен җәлеп ителгән кредит һәм (яки) бүтән төрле заем акчалары;

күпфатирлы йортларның капиталь ремонт фондларын формалаштыру – махсус счетта торучы акча рәвешендә капиталь ремонт фонды формалаштыру максатларында махсус счетка капиталь ремонт өчен кертемнәр күчерү, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең төбәк операторына карата йөкләмә хокуклары рәвешендә капиталь ремонт фонды формалаштыру максатларында төбәк операторы счетына капиталь ремонт өчен кертемнәр күчерү;

биналарның милекчеләре тарафыннан махсус счетта фонд формалаштыру ысулының сайлануы турында хәбәрләмә – тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыруның сайланган ысулы турында хәбәр итүне үз эченә алган, имзаланган һәм мөһер белән таныкланган документ, аны махсус счет иясе махсус счет ачылган вакыттан башлап биш эш көне эчендә, биналарның милекчеләренең РФ ТК 170 статьясының 3 һәм 4 өлешләрендә каралган карарларны кабул итү турында гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен һәм махсус счет ачу турында банктан белешмә күчермәсен зарури теркәп, билгеләнгән формада (1 нче кушымта) ТР ДТИ тапшырырга тиеш;

махсус счет ачу турында хәбәр – махсус счет ачу турында банк белешмәсе күчермәсе, ул күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган махсус счетта капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмә белән бергә ТР ДТИ җибәрелә;

хәбәрләмләр реестры – күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган махсус счетта капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында ТР ДТИ алынган барлык хәбәрләмәләр реестры;

махсус счетлар реестры – ачылган, капиталь ремонт фондын формалаштыру өчен билгеләнгән махсус счетлар реестры;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сайланмаган күпфатирлы йортлар турында белешмәләр – биналарының милекчеләре тарафыннан капиталь

ремонт фондын формалаштыру ысулы сайланмаган һәм (яки) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында ТКХ ДМС алынган, ТР ДТИ тарафыннан Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, шулай ук җирле үзидарә органына һәм төбәк операторына җибәрелә торган мәгълүмат.

## 2. Төбәк операторы, махсус счет иясе тарафыннан ТКХ ДМС кертелергә тиешле белешмәләр

2.1. ТКХ ДМС системасында түбәндәге белешмәләр буенча исәпкә алу һәм хисаплылык формалаштыру башкарыла:

а) тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган махсус счетта капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмәләрне реестр рәвешендә исәпкә алу;

б) күпфатирлы йортларның махсус счетларын реестр рәвешендә исәпкә алу;

в) күпфатирлы йортта махсус счетта капиталь ремонт фонды формалаштыручы милекчеләрдән капиталь ремонтка кертемнәр түләү турында белешмәләрне исәпкә алу;

г) күпфатирлы йортта махсус счетта капиталь ремонт фонды формалаштыручы биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәрнең күчүе турында белешмәләрне исәпкә алу;

д) махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акча күләме турында белешмәләрне исәпкә алу;

е) махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йортларның махсус счетында акчаның калдык өлеше турында белешмәләрне исәпкә алу;

ж) капиталь ремонт уздыруга займ шартнамәсе һәм (яки) кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләрне исәпкә алу;

з) биналарының милекчеләре махсус счетта һәм төбәк операторы счетында, счетларында капиталь ремонт фонды формалаштыра торган күпфатирлы йортлар турында белешмәләрне исәпкә алу (күпфатирлы йортларның катлары, гомуми мәйданы, күпфатирлы йортта торак бүлмәләрнең мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы);

и) күпфатирлы йортларда төбәк операторы счетында, счетларында капиталь ремонт фонды формалаштыручы биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәрнең күчүе турында белешмәләрне исәпкә алу;

к) җирле үзидарә органына һәм төбәк операторына биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондларын формалаштыру ысулын сайламаган һәм (яки) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында мәгълүмат җиткерү өчен җыелма хисап формалаштыру;

л) Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, шулай ук җирле үзидарә органына мәгълүмат җиткерү максатында, капиталь ремонт фондын формалаштыруга күзәтчелек өлешендә ТР ДТИ эшчәнлеге турында җыелма хисаплар формалаштыру.

## 3. Күпфатирлы йортларның капиталь ремонт фондын формалаштыру турында мәгълүмат кертү тәртибе

3.1. Махсус счет иясе теркәлүче форма (1 нче кушымта) нигезендә махсус счет ачылган вакыттан башлап биш эш көне эчендә ТКХ ДМС системасында түбәндәгеләрне урнаштыра:

тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында хәбәрләмә, РФ ТК 170 статьясының 3 һәм 4 өлешләрендә каралган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре күчермәләрен теркәп;

махсус счет ачу турында банк белешмәсен;

күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен;

күпфатирлы йорт турында мәгълүматлар (катлар саны, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йортта торак урыннар мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы). Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләрен рәсмиләштерүгә карата таләпләр һәм күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары карарлары һәм беркетмәләре күчермәләрен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма хакимият органнарына тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 937/пр номерлы боерыгы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

Махсус счет иясе махсус счет ачылган вакыттан башлап биш эш көне эчендә ТР ДТИ түбәндәгеләрне кәгазьдә тапшыра:

тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмә;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында әлеге күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе күчермәсен;

махсус счет ачу турында банк белешмәсе күчермәсен.

3.2. ТКХ ДМС системасында махсус счет иясе тарафыннан, ай саен, хисап

аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр, теркәлүче форма (5 нче кушымта) нигезендә түбәндәгеләр урнаштырыла:

капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында күчерелгән акча күләме турында мәгълүмат;

капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә күчерелгән акча күләме турында мәгълүмат;

махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акча күләме турында мәгълүмат;

махсус счетта акчаның калдык өлеше турында мәгълүмат;

капиталь ремонт уздыруга займ шартнамәсе һәм (яисә) кредит шартнамәсе төзү турында мәгълүмат, мондый шартнамәләрнең таныкланган күчермәләрен теркәп.

Әгәр күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын төбәк операторы счетында формалаштыруны һәм капиталь ремонт фондын махсус счетта формалаштыруны туктату турында карар кабул итсә, ул вакытта РФ ТК 173 статьясының 5 өлешендә билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә махсус счет иясе түбәндәгеләрне ТКХ ДМС системасында урнаштыра һәм ТР ДТИ кәгазьдә тапшыра:

тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмә;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында әлеге күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе күчермәсен;

махсус счет ачу турында банк белешмәсе күчермәсен.

3.3. Капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында күчерелгән акча күләме турында белешмәләр РФ ТК 175 статьясының 3.1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан махсус счет иясенә ай саен, хисап аеннан соң килүче айның бишенче көненә кадәр тапшырыла, шул исәптән электрон рәвештә, 5 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча.

3.4. Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын төбәк операторының махсус счетында формалаштыру ысулын сайлау турында карар кабул иткән очракта, төбәк операторы махсус счет иясе буларак, кушымтада бирелгән форма (1 нче кушымта) нигезендә биш эш көне эчендә ТКХ ДМС системасында түбәндәгеләрне урнаштыра:

тиешле күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмә;

фондны формалаштыру ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен;

махсус счет ачу турында банк белешмәсен;

күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен;

күпфатирлы йорт турында мәгълүматлар (катлар саны, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йортта торак урыннар мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы).

3.5. Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын төбәк операторының махсус счетында формалаштыру ысулын сайлау турында карар кабул иткән очракта, төбәк операторы махсус счет иясе буларак, ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр, кушымтада бирелгән формалар (5 нче кушымта) нигезендә, ТКХ ДМС системасында түбәндәгеләрне урнаштыра:

капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында күчерелгән акча күләме турында мәгълүматны;

капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә күчерелгән акча күләме турында мәгълүматны;

махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акча күләме турында мәгълүматны;

махсус счетта акчаның калдык өлеше турында мәгълүматны;

капиталь ремонт уздыруга займ шартнамәсе һәм (яисә) кредит шартнамәсе төзү турында мәгълүматны, махсус счет иясенең мондый шартнамәләренең таныкланган күчермәләрен теркәп.

3.6. Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын төбәк операторы счетында формалаштыру ысулын сайлау турында карар кабул иткән очракта, төбәк операторы хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр ТКХ ДМС системасында түбәндәгеләрне урнаштыра:

капиталь ремонт фонды төзү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышыннан беркетмә күчермәсен;

күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен;

капиталь ремонт фонды формалаштыру турында һәм капиталь ремонт уздыруны оештыру турында шартнамә күчермәсен;

күпфатирлы йорт турында белешмәләр (катлар саны, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йортта торак урыннар мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы һ.б.);

биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр килүе турында белешмәләр.

3.7. Әгәр күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламаса яки алар сайлаган ысул законда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырылмаса, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органы мондый йортка карата төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды оештыру турында карар кабул итә.

Җирле үзидарә органы тарафыннан төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды оештыру турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә идарәче оешма (ИК, ТМШ, ТТК) яисә йорт советы рәисе (турыдан-туры идарә иткәндә) ТКХ ДМС системасында түбәндәгеләрне урнаштыра:

җирле үзидарә органының төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды оештыру турында карарын раслаучы документ күчермәсен;

күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен;

капиталь ремонт фонды формалаштыру турында һәм капиталь ремонт уздыруны оештыру турында шартнамә күчермәсен.

3.8. ТР ДТИ кушымтада бирелгән формалар (2 нче, 3 нче кушымталар) хәбәрләмәләр реестрын, махсус счетлар реестрын алып бара.

3.9. РФ ТК 170 статьясының 5 һәм 5.1 өлешләрендә билгеләнгән сроклар узгач, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында карар кабул итү һәм сайланган ысулны гамәлгә ашыру өчен, ТР ДТИ капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулын сайламаган һәм (яки) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында мәгълүматны кушымтада бирелгән форма (4 нче кушымта) буенча җирле үзидарә органнарына һәм төбәк операторы адресына җибәрә.

3.10. ТР ДТИ Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына капиталь ремонт фондын формалаштыруга контроль турындагы белешмәләрне әлеге федераль орган билгеләгән тәртиптә тапшыра.

Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә

______________________________________________________________

(почта адресы)

ХӘБӘРЛӘМӘ

махсус счет иясеннән яки төбәк операторы исеменә түбәндәге адрес буенча күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен ачылган махсус счет иясеннән:

______________________________________________________________________________________,

банкта махсус счет ачу турында

(счетны ачкан көннән соң 5 эш көне узганчы җибәрелә)

«__» ________ 20__ ел.

Оешу-хокук формасы: ______________________________________________________

______________________________________________________________________________________

Махсус счет иясе: _________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

(оешманың тулы аталышы)

ИНН ___________________ КПП __________________________

ОКТМО ______________________ ОГРН ____________________________

Махсус банк счеты ачылуы турында хәбәр итә:

Банк _____________________________________________________________________

(банкның тулы аталышы)

Банкның ИНН _______________________________________

Банкның КПП _______________________________________

Банкның ОГРН ______________________________________

Банкның БИК ________________________________________

Банкның корреспондент счеты _________________________________________

Махсус счет номеры ___________________________________

Махсус счет ачу датасы

«__» ________ 20__ ел.

Махсус счет иясенең оешма җитәкчесе

______________________________________________

___________________________________________________________________________

(вазыйфа, ФИА, имза)

МУ
Кушымта:
1. Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында әлеге күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе күчермәсе, 1 нөс.
2. Махсус счет ачылуы турында банк белешмәсе күчермәсе, 1 нөс.

Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслашкан коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләр тапшыру тәртибенә 2 нче кушымта

Биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фонды формалаштыру ысулы турында хәбәрләмәләр
РЕЕСТРЫ
201___ елның «___» __________ торышына

| Муниципаль берәмлек | адресы | Махс. счет иясенең аталышы | Почта адресы | ОГРН | ИНН | ОКТМО | КПП | ДТИ теркәлү датасы | ДТИ теркәлү номеры | Хәбәр итү датасы | КР фонды (махсус счет, төбәк операторы исеменә махсус счет) | Фондны формалаштыру ысулын сайлау турында милекчеләрнең гомуми җыелышы беркетмәсе датасы | Махсус счет ачу датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |

Күпфатирлы
ремонт уздыр
эшчәнлекне 
коммерциясе
махсус счет и
Республикасы
белешмәләр 

Махсус счетлар РЕЕСТРЫ
20___ елның «___» __________ торышына хисап

| Муниципаль берәмлек | адресы | Махс. счет иясенең аталышы | Махс. счет № | Ачу датасы | Ябу датасы | Банк аталышы | Банкның почта адресы | Банкның ИНН | Банк КП |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 1 |

Күпфатирлы
ремонт узды
эшчәнлекне
коммерцияс
махсус счет
Республикас
белешмәләр

Биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламага

БЕЛЕШМӘЛӘР

20___ елның «___» _____________ торышына хисап

| № | Муниципаль берәмлек | адресы | Идарәче оешманың оешу-хокукый формасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |

Күпфатирлы й
ремонт уздыру
эшчәнлекне га
коммерциясез
махсус счет ия
Республикасы
белешмәләр та

Махсус счетта күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау фондын формалаштыручы
белешмәләре

| № | Күрсәткеч |
|---|---|
| **Капиталь ремонт фондын төзү ысулы турында белешмәләр** | |
| | Биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сыйфатында махсус счетк<br>өчен кертемнәр күчерүне сайлаган һәм гамәлгә ашырган КФЙ биналарының мәйданы, махсус счетның и |
| 1 | ТО |
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |
| 5 | Биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сыйфатында кертемнәрне ТО<br>(счетларына) күчерүне сайлаган КФЙ биналарның мәйданы |
| **Капиталь ремонтка кертемнәр күчүе турында белешмәләр** | |
| | Махсус счетларга КФЙ буенча капиталь ремонт өчен кертемнәр исәпләнүе турында белешмәләр, бу счет |
| 1 | ТО |
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |
| 5 | КФЙ буенча капиталь ремонтка кертемәрнең ТК күмәк счетына (счетларына) исәпләнүе турында белешм |
| **КФЙ биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр килүе турында белешмәләр** | |
| | КФЙ биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт өчен махсус счетка кертемнәр килүе турында белеш<br>счетның иясе: |
| 1 | ТО |

| | |
|---|---|
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |



| | |
|---|---|
| 5 | КФЙ биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт өчен ТК күмәк счетына (счетларына) кертемнәр ки<br>белешмәләр |
| **Капиталь ремонтка акча тоту турында белешмәләр** | |
| | Махсус счетларга КФЙ буенча капиталь ремонт өчен акча тоту турында белешмәләр, бу счетларның иял |
| 1 | ТО |
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |
| 5 | КФЙ буенча капиталь ремонт өчен ТК күмәк счетыннан (счетларыннан) акча тоту турында белешмәләр: |
| **Капиталь ремонт фондында акчаның калган өлешенең күләме турында белешмәләр** | |
| Махсус счетта акчаның калган өлешенең күләме турында белешмәләр, аның иясе: | |
| 1 | ТО |
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |
| 5 | ТК күмәк счетында (счетларында) акчаның калган өлешенең күләме турында белешмәләр |
| **Капиталь ремонт уздыру өчен кредитлар (займнар) җәлеп итү турында белешмәләр** | |
| | КФЙ капиталь ремонт уздыруга кредит шартнамәләре һәм (яки) займ шартнамәләре буенча түләнергә ти<br>турында белешмәләр, аларда махсус счет иясе: |
| 1 | ТО |
| 2 | ТМШ |
| 3 | ТК |
| 4 | ИК |
| | Капиталь ремонт уздыруга кредит шартнамәләре һәм (яки) займ шартнамәләре буенча түләү бурычы бул<br>турында белешмәләр, аларда махсус счет иясе: |
| 5 | ТО |
| 6 | ТМШ |
| 7 | ТК |
| 8 | ИК |
| | Капиталь ремонт уздыруга кредит шартнамәләре һәм (яки) займ шартнамәләре буенча бурычлары булган<br>биналарының мәйданы турында белешмәләр, аларда махсус счет иясе: |

| | |
|---|---|
| 9 | ТО |
| 10 | ТМШ |
| 11 | ТК |
| 12 | ИК |